РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 24 2025 елның 12 декабре

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль берәмлек Уставы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы, муниципаль милектән файдалану һәм аның белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карарына (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 10 бүлегенең 10.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Килешү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 10.1 пунктында санап үтелгән гаризалар нигезендә, мондый гаризаны бирү ысулына карап, күрсәтелгән вариантларның берсе итеп рәсмиләштерелә:

- аерым күрсәтмә чыгару юлы белән (кәгазь чыганакта гариза бирелгән очракта);

- «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасында килешүне килештерү турында резолюция салу юлы белән (электрон документ әйләнеше системасында гариза бирелгән очракта).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеше, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.И. Беляев